**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының
Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

2026 елның 15 июленнән № 18

Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ Федераль законның 55 статьясы, «Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге № 14-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге № 92-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгы белән төзелгән 2026 елның 12 гыйнварындагы Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә түбәндәгеләр карар итте:

1. Муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү эше барышында Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында Килешү белән җитәкчелек итәргә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге муниципаль норматив хокукый актлары юнәлеше өчен җаваплы, шулай ук регистрга кертелергә тиешле алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең башкарма комитеты сәркатибе итеп билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле

авыл җирлеге башкарма комитетының 30.12.2015 № 27 Карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлегенең
башкарма комитеты җитәкчесе Җ.Г. Гайфетдинов